Шәһәр күләмендә Татар халкы һәм Татарстан тарихы фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың шәһәр этабы биремнәре
2024-2025 нче уку елы
9 сыйныф

Эшне башкару вакыты – 90 минут
Гомуми балл – 70

1 бүлек. Тәкъдим ителгән җаваплар арасыннан дөресен сайлап алыгыз.
(Һәр дөрес җавап өчен 1 б. Иң югары – 5 б.)

1. “Кыскача Казан тарихы” һәм “Статистик һәм этнографик яктан Казан татарлары” хезмәтләре авторы: (1 б.)
А) Х.Д.Френ
Б) К.Ф.Фукс
В) Д.И.Мейер
Г) Э.П.Перцов
Җавап: _____

2. Казан губернасы ничәнче елда оеша? (1 б.)
А. 1708 елда;
Б. 1714 елда;
В. 1718 елда;
Г. 1719 елда.
Җавап: _____

3.Борынгы чорда нинди диңгез «Хәзәр диңгезе» дип аталган? (1 б.)
А. Кара диңгез.
Б. Каспий диңгезе.
В. Чукот диңгезе.
Г. Баренц диңгезе.
Җавап: _____

4. Алтын Урда дәверендә иҗат ителгән «Нәһҗел Фәрадис» исемле әсәрнең авторын атагыз. (1 б.)
А. Кол Гали
Б. Сәйф Сараи
В. Мәхмүд Болгари
Г. Мөхәммәдьяр
Җавап: _____

5. Беренче төрки-татар газетасының исеме ничек? (1 б.)
А. “Тәрҗеман”.
Б. “Салават күпере”.
В. “Нур”.
Г. “Вакыт”.
Җавап: _____

2 бүлек. Туры китерүгә, эзлеклелекне, артык элементны, дөрес бәяләмә һ.б. билгеләүгә нигезләнгән биремнәр

6. Атамаларны мәгънәләре белән туры китерегез. (Һәр дөрес җавап өчен 1 б., иң югары – 7 б.)

Атама	Мәгънәсе
А. тамгачы	1. Төрки дәүләтләрдә югары хаким титулы, “ханнар ханы”, император.
Б. неофит	2. Алтын Урда һәм татар ханлыкларында таможня тикшерүчесе
В. сәед	3. Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән булган кеше
Г. приказщик	4. Берәр нинди диннең яңа тарафдары
Д. угълан	5. Җирле идарә башлыклары.
Е. каһан	6. Чыңгыз хан нәселеннән булган тәхет варисы, солтан.
Ж. баскак	7. Татар бистәсенә куелган рус түрәләре.

Җавап:

А	Б	В	Г	Д	Е	Ж

7. Исемлектә китерелгән артык шәхесне билгеләгез. (2 б.)

А. Мәгубә Сыртланова
Б. Фәрит Яруллин
В. Михаил Девятаев
Г. Фәрит Фәткуллин

Җавап: _____

8. Түбәндә тарихи терминнар китерелгән. Аларны дөрес һәм дөрес булмаганнарга аерыгыз. Җавапларыгызны таблицага языгыз. (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 б. Иң югары – 8 б.)

1) Диван – дәүләт шурасы, хан кул астындагы, дәүләтнең мөһим мәсьәләләрен хәл итүче аз санлы өстен катлау аксөякләр төркеме.
2) Баскак – тоткын.
3) Ям – дәүләт почта станциясе, татар дәүләтләрендә ат алыштыру һәм ял итү пункты.
4) Урда – тәхет варисы титулы, каһан улы.
5) Тархан – мираска калган һәм шартлар белән чикләнмәгән биләмә.
6) Адъюнкт – кече галимлек вазифасы.
7) Иганә – йолдызлар системасы.
8) Китайка – Кытайның ефәк тукымасын хәтерләтүче мамык тукыма.

Җавап:

Дөрес	Ялгыш

9. Вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. (Тулы дөрес җавап өчен 6 б.)

А) Казанда Икенче ирләр гимназиясе ачыла.	
Б) Алтын Урданың таркалуы.	
В) Идел буе Болгар дәүләтенең татар-монголлар тарафыннан алынуы.	
Г) Казан шәһәренә нигез салына.	
Д) Казанда Родионованың затлы нәсел кызлары институты ачыла.	
Е) Степан Разин җитәкләгән кузгалыш.	

10. Тарихи төшенчәләрне тасвирламалары белән туры китерегез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 б., иң югары – 5 б.)

Төшенчә	Тасвирлама
1) Җәдитчелек	А) Сәяси эчтәлектәге агитацион язма
2) Прокламация	Б) Татар иҗтимагый тормышының төрле өлкәләрен яңартуга юнәлдерелгән иҗтимагый-сәяси хәрәкәт
3) Соборное уложение	В) килүшеләрне раслаучы төрле дипломатик юллама һәм язма антлар
4) Шартнамә	Г) Россия дәүләтенең крепостной хокукны юридик яктан закон көченә керткән 1648 елгы кануннар җыелмасы
5) Татар ратушасы	Д) Казанда татар бистәләренең үзидарә органы

Җавап:

1	2	3	4	5

11. Исемлектә китерелгән артык элементны билгеләгез. Җавабыгызны дәлилләгез (Һәрбер дөрес күрсәтелгән элемент өчен 1 б., җавапны дәлилләү 1 б., иң югары 8 б.).

А) Туктамыш, Үзбәк, Аксак Тимер, Җанибәк.

Җавап:_____

_____

Б) Казан ханлыгы, Кырым ханлыгы, Әстерхан ханлыгы, Идел Болгары, Ногай Урдасы, Себер ханлыгы.

Җавап:_____

_____

В) Мөхәммәдъяр, Өмми Камал, Кол Шәриф, Сәйф Сараи.

Җавап:_____

_____

Г) Солтан, морза, хан, сәет, ясак, вәзир.

Җавап:_____

_____

12. Түбәндә китерелгән төшенчәләргә дөрес билгеләмәләр бирегез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б., иң югары – 10 б.)

А. Мөһаҗирләр хәрәкәте

Җавап: _____

_____

Б. Иттифак әл-мөслимин

Җавап: _____

_____

В. Казан коммунасы

Җавап: _____

_____

Г. Гильдия

Җавап: _____

_____

Д. Писцовый кенәгә

Җавап: _____

_____

3 бүлек. Рәсемнәр белән эшләүгә нигезләнгән биремнәр

13. Рәсемнәрдә күрсәтелгән Казан шәһәренең тарихи урын һәм биналарын исемнәре белән туры китерегез. Җавапны түбәндә китерелгән таблицада языгыз. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б. Иң югары 8 б.).

А	 Б
 В	Г

1. Благовещение соборы.
2. Дворян собраниесе.
3. М.-Ш. Шамил йорты.
4. Шамов больницасы.

Җавап:

А	Б	В	Г

4 бүлек. Чыганак текстлары белән эшләүгә нигезләнгән биремнәр

14. Түбәндә китерелгән өзекне укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез. (Иң югары 11 б.).

Казан университетында ирекле тыңлаучы булып укучы энциклопедист галим була. Татар халкын китаплар ярдәмендә мәгърифәтле итү аның төп эшенә әверелә. Үзенең әллә ни күп булмаган акчасын ул тулысы белән үзе язган әсәрләрне нәшер итүгә һәм аларны халык арасында таратуга сарыф итә. Болар - татарлар өчен чыгарылган математика, тарих, географиядән беренче дәреслекләр, беренче татар сүзлеге һәм төрле фән тармаклары буенча китаплар. Аның тарафыннан чыгарыла торган календарьларны белемнең төрле өлкәләре буенча кечкенә энциклопедияләр диярга мөмкин. Аларда Казан, Казан ханлыгы, Россия тарихы, медицина, педагогикага кагылышлы әһәмиятле мәгълүматлар туплап бирелә. Үз календарьлары өчен күпсанлы географик карталар да сыза. Татар балаларын русча укырга-язарга өйрәтүче беренче мәктәпне ача. Ул шулай ук рус уку йортларында татар теле укыта. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы итеп сайлана.

Текстта кем турында сүз бара? (2 б.).

Җавап: _____

2025 елда әлеге шәхеснең тууына ничә ел була? (3 б.).

Җавап: _____

Ул нинди матур әдәбият әсәрләре авторы? (Һәрбер әсәр исеме өчен 2 б., иң югары 6 б.).

Җавап:

_____

_____

УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ!